# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**21 ноябрь 2019 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2019 елның 21 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләренә таянып, түбәндәге мәсьәлә буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Тәтеш картлар һәм инвалидлар интернат йорты» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесеннән социаль хезмәт алучылар, күпбалалы гаиләләр, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм аларның тол хатыннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, иректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Олы Шәмәк авылы эчендәге Мәктәп ур., Пролетарская ур., Ленин ур., Кутузов ур., Совет ур. юлларны төзекләндерү;

- Олы Шәмәк авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу;
- Олы Шәмәк авылында урам яктырткычлары һәм лампалары сатып алу һәм алыштыру;
- Олы Шәмәк авылына чүп контейнерлары сатып алу;
- Олы Шәмәк авылында карт агачларны кисү ?».

««РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булучы җыенда катнашучылар исемлегенә 419 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 252 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 248 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Әлеге мәсьәлә буенча: «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Тәтеш картлар һәм инвалидлар интернат йорты» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесеннән социаль хезмәт алучылар, күпбалалы гаиләләр, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм аларның тол хатыннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар,

ипректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш,   2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм  аннан алынган акчаларны  җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез  риза буласызмы:

- Олы Шәмәк авылы эчендәге Мәктәп ур., Пролетарская ур., Ленин ур., Кутузов ур., Совет ур. юлларны төзекләндерү;
- Олы Шәмәк авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу;
- Олы Шәмәк авылында урам яктырткычлары һәм лампалары сатып алу һәм алыштыру;
- Олы Шәмәк авылына чүп контейнерлары сатып алу;
- Олы Шәмәк авылында карт агачларны кисү ?».

««РИЗА»                                    «КАРШЫ»

карар кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **А.И. Афанасьев**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Шәмәк авыл җирлеге башлыгы** **А.И. Афанасьев**